РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОУСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

**ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**Яңа Усы авылы** **«15» ноябрь 2024 ел**

# КАРАР №17

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге территориясендә 2024-2025 елларның кышкы чорында карны вакытлыча җыю урыннарын билгеләү турында

Интенсив кар яву чорында юлларны һәм урамнарны кардан вакытында чистартуны тәэмин итү, 2024-2025 елларның кышкы чорында Яңа Усы авыл җирлегендә территорияне чистартуны тәртипкә салу һәм вакытлыча кар җыю урыннарын билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Яңа Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. 2024-2025 елларның кышкы чорында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге территориясендә вакытлыча кар җыю өчен ачык мәйданчыклар сыйфатында түбәндәге территорияләрне билгеләргә:

Яңа Усы авылында урнашкан 16:29:080102:202 кадастр номерлы җир кишәрлеге янәшәсендәге 300,00 кв. м мәйданлы буш кишәрлектә ;

Бикмәч авылында урнашкан 16:29:080201:55 кадастр номерлы җир кишәрлеге янәшәсендәге 100,00 кв. м мәйданлы буш кишәрлектә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлеге рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Мөслим муниципаль районы**
**Яңа Усы авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе:** **Г.С.Романова**